Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче Яңа Кармәт авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

2021 елның 19 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елның № 131 - ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының "Яңа Кармәт авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2019 елның 5 ноябрендәге 98 номерлы карарына таянып, түбәндәге сораулар буенча 2021 елның 16 нояберендә һәм 19 ноябрендә Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегененЯңа Кармәт авылында узган гражданнар җыены этаплары нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

1."2022 елда Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге Яңа Кармәт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә килешәсезме:

1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Яңа Кармәт авылы Жданов, Карл Маркс, Тукай, Кызыл армия, Зеленая урамнарына таш һәм ташлы грунт сатып алу;

-Яңа Кармәт авылы эчендәге юлларны кышкы чорда карап тоту, Муса Җәлил, Жданов, Тукай, Кызылармия, Карл Маркс, Зеленая урамнарын кардан чистарту буенча килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.

2) Җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру

- Яңа Кармәт авылы зиратында агач кисү килешүе буенча хезмәт өчен түләү

"ӘЙЕ" " ЮК" "ТЫЕЛЫП КАЛДЫ"

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган214 гражданин кертелгән, тавыш бирүдә 136 гражданин катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 110 кеше тавыш бирде;
- «юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 26 кеше тавыш бирде.
- "тыелып калды" позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче Яңа Кармәт авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре-чын.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә:
1."2022 елда Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге Яңа Кармәт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә килешәсезме:
1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Яңа Кармәт авылы Жданов, Карл Маркс, Тукай, Кызыл армия, Зеленая урамнарына таш һәм ташлы грунт сатып алу;
-Яңа Кармәт авылы эчендәге юлларны кышкы чорда карап тоту, Муса Җәлил, Жданов, Тукай, Кызылармия, Карл Маркс, Зеленая урамнарын кардан чистарту буенча килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.
2) Җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру
- Яңа Кармәт авылы зиратында агач кисү килешүе буенча хезмәт өчен түләүґ
3. Әлеге карарны Яңа Кармәт авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка җиткерергә,http://aksubaevo.tatar.ru Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәмhttp://pravo.tatarstan.ru/Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.
4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгы И. Р. Шакиров